ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

№ 7 — 02 апрель 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ санлы Федераль законның 13.4 маддәсе, 2018 елның 31 августындагы «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1039 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- №1 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын.

- 2 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 29 июнендәге «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында»гы 18 санлы карары үз көчен югалткан дип таныырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.


4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев

2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары схемасы







р. Акчишма


Урал
Уральская ул.
Неизвестный солдат
Восточная ул.
Дорожная ул.
Дорожная ул.


ул. Каран-Чишма